**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 29 гыйнварындагы ПУ-80 номерлы, 2014 елның 10 февралендәге ПУ-132 номерлы, 2014 елның 5 мартындагы ПУ-244 номерлы, 2014 елның 20 мартындагы ПУ-286 номерлы, 2014 елның 19 апрелендәге ПУ-405 номерлы, 2014 елның 26 апрелендәге ПУ-435 номерлы, 2014 елның 2 июлендәге ПУ-636 номерлы, 2014 елның 12 сентябрендәге ПУ-854 номерлы, 2014 елның 28 ноябрендәге ПУ-1091 номерлы, 2014 елның 5 декабрендәге ПУ-1107 номерлы, 2015 елның 16 мартындагы ПУ-289 номерлы, 2015 елның 18 мартындагы ПУ-294 номерлы, 2015 елның 25 мартындагы ПУ-367 номерлы, 2015 елның 17 июнендәге ПУ-562 номерлы, 2015 елның 26 июнендәге ПУ-602 номерлы 2015 еның 29 июлендәге ПУ-680 номерлы, 2015 елның 10 сентябрендәге ПУ-850 номерлы, 2015 елның 24 сентябрендәге ПУ-892 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 6 апрелендәге ПУ-331 номерлы, 2016 елның 19 апрелендәге ПУ-366 номерлы, 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2016 елның 6 декабрендәге ПУ-1075 номерлы, 2016 елның 23 декабрендәге ПУ-1192 номерлы, 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1228 номерлы, 2017 елның 15 февралендәге ПУ-143 номерлы һәм 2017 елның 27 апрелендәге ПУ-345 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктта «135» санын «136» санына алмаштырырга;

б) 6 пунктта «10» санын «11» санына алмаштырырга;

в) 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «19 | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, | 356 |
| | шул исәптән: | |
| | министрлык аппараты | 196 |
| | территориаль органнар | 160». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ, 2017 елның 1 октябреннән үз көченә керүче 1 пунктның «в» пунктчасыннан кала, аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 03 июнь
№ ПУ-456